КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1317

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 ел, 31 декабрь, 920 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 ел, 31 декабрь, 920 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 август, 712 нче, 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 27 август, 625 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1, 1.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Нигезләмә «Электрон санлы имза турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 1-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарында эш башкару кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 15 июнендәге 477 нче карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы турындагы

нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 22 сентябрендәге 754 нче карары, «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында электрон документ әйләнешенең бердәй ведомствоара системасы турында» 2009 елның 5 февралендәге ПУ-52 номерлы Указы нигезендә эшләнде.

1.2. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында электрон санлы имза чаралары белән якланган электрон документлар алмашу тәртибен билгели.»;

2.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.19. Электрон документларны БВЭДС эчке контурында саклауның билгеләнгән вакыты чыкканнан соң мәҗбүри тәртиптә электрон документларның кәгазь документларына да шундый ук кыйммәт экспертизасы үткәрелә.

Кыйммәт экспертизасы нәтиҗәләре буенча БВЭДС катнашучысы җитәкчесе раслый торган юкка чыгарылырга бүлеп бирү турында акт нигезендә актка кертелгән электрон документлар юкка чыгарылырга (бетерелергә) тиеш.

Вакытлыча саклау вакыты тәмамлангач (кәгазь йөртүчеләренә охшаш документлар) электрон документлар әлеге Нигезләмәнең 2.18 пункты нигезендә мәгълүматлар җыелмасын алып баручы БВЭДСның "Оешмасы архивы" модуленә саклануга тапшырыла.

«Оешма архивы» модулендә вакытлыча саклау срогы чыккач электрон документлар БВЭДС ярдәмендә Татарстан Республикасы бердәм архив мәгълүмат системасының «Дәүләт архивы» модуле аша тиешле дәүләт яисә муниципаль архивка саклануга шундый ук кәгазьдәге документларга тапшырыла.»;

2.21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.21. Электрон документларны исәпкә алу һәм эзләү максатларында, Бердәм ведомствоара системада электрон документлар турындагы түбәндәге мәҗбүри мәгълүматлар файдаланыла:

адресант (автор);

адресат;

документка кул куйган затның вазыйфасы, инициаллары һәм фамилиясе;

документ төренең исеме;

документ датасы;

документны теркәү номеры;

керүче документны теркәү датасы;

керүче документны теркәү номеры;

бәйләнгән документлар турында мәгълүматлар (документ датасы, теркәү номеры, Ф.И.Ә.ию һәм имза куючы вазыйфасы);

текстның атамасы (документның кыскачы эчтәлеге);

делолар номенклатурасы буенча дело индексы;

төп документның битләре саны;

кушымта турында тамга (кушымта битләренең гомуми саны);

документны үтәү буенча күрсәтмәләр (үтәүче, йөкләмә, үтәү датасы);

карауны чикләү грифы;
электрон имза турында белешмәләр;
документны җаваплы үтәүче.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин